КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 8 декабрь г.Казань № 1579

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 23 сентябрь, 910 нчы карары белән расланган Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 23 сентябрь, 910 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1363 нче; 2022 ел, 21 март, 251 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә, 8.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле «г» һәм «д» пунктчаларын өстәп, үзгәреш кертергә:

«г) алты ай рәттән гражданнардан, юридик затлардан, индивидуаль эшмәкәрләрдән, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан һәм мәгълүматның башка мәгълүмат чыганакларыннан алынган хәбәрләр нигезендә контрольдә тотылучы зат тарафыннан булдырылган (бирелгән) квоталы эш урыннарының гомуми санынннан квоталы эш урыннарын биләгән, эшкә урнашкан инвалидлар санын 50 проценттан күбрәк кимету;

д) гражданнардан, юридик затлардан, индивидуаль эшмәкәрләрдән, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан һәм мәгълүматның башка мәгълүмат чыганакларыннан алынган хәбәрләр нигезендә контрольдә тотылучы затның эш урыннарын 30 проценттан күбрәк арттыру яки җитештерү куәтен җәелдерү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин